Рифкать Имаев

# Агымсу

Шигырьләр

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2012

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
И48

**Имаев, Р. Г.**

Агымсу : шигырьләр / Рифкать Имаев. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2012. – 127 б.
ISBN 978-5-298-02210-1

Шагыйрьнең әлеге китабына төрле елларда иҗат ителгән лирик шигырьләре туплап бирелде.

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-02210-1
© Татарстан китап нәшрияты, 2012
© Имаев Р. Г., 2012

# Күңелнең бөек мәле

## АГЫМСУ

Агымсулар акмый тормый,
Аккан сулар болгана.
Җаннарында сагыш булган
Суга карап моңлана.

Агымсулар акмый тормый,
Аккан суның үз юлы.
Узып бара тагын минә
Гомеремнең бер елы.

Агымсу ич, болганадыр,
Болгана да бер тона.
Елгалар да безнең төсле
Бер ашыга, бер тына.

Йөзгән чагым колач салып
Тормыш дигән агымда.
Көтәләрдер, ярга басып,
Иртән туган ягымда.

Агыздым да агымында,
Калдым сагыштан бушап.
Сабырландым, салмакландым,
Агымсуларга охшап.

## АВГУСТ КИЧЕ

Кояш әле шәп кыздыра,
Суынмаган яккан мичe.
Кереп килә авылыма
Алма исле август киче.

Өретелгән томан белән
Каршымдагы инеш өсте.
Авызларда эрер булып,
Бакчаларда алма пеште.

Сөбханалла бүгенгесе,
Болай тормас гелән-гелән.
Каеннары, юкәләре
Яфрак кояр берәм-берәм.

Елына дүрт алышына

Безнең якта яшәү шарты.
Һава сулый бүген кичен
Авылымның яше-карты.

Җитте менә җылы җәйнең
Кабатланмас серле киче –
Агып чыга урамнарга
Бакчалардан алма исе.

## НИГӘ ШУЛАЙ?

Чит илләрнең юллары да
Үзе шома, үзе такыр.
Бездәгесе бездәгечә –
Адым саен чокыр-чакыр.

Чыгалар да микрофонга
Бертуктаусыз мактаналар,
Эшләнәсен эшләдек, дип,
Безнең алда акланалар.

Намус саклыйм дия-дия,
Сызып кына гомер үтә.
Каршы чыгып әйтер идең,
Бу эш бездә начар бетә.

Өч кенә мең бирсәләр дә,
Түлиләр дип шатланабыз.
Кимемәсен халык дисәк,
Юлда безне таптамагыз.

Йөз миллион урлаганнар
Бер җәзасыз котылалар,
Йөз сум белән тотылганнар
Төрмә тулып утыралар.

«Дөнья – тоташ базар» диләр,
Безнеке тик аермалы –
Йә, кайда бар түрәләрнең
Бездәгедәй баеганы?

## ТУЯ АЛГАНЫМ ЮК

Язмыш елгаларын кичәм,
Ачы яше битне юа.
Ял итәргә вакыт тими,
Чыбыркылап тормыш куа.

Шигырьләргә чыкты саркып

Әйталмаган йөрәк зары.
Бер тукталып алыйм дисәм –
Офыклары дәште ары.

Язмыш елгаларын кичәм:
Суы – тирән, яры – биек.
Тордым зират яннарында
Шактый гына, башны иеп.

Ял итәсе килә кайчак,
Җир-анага башны куеп.
Тик язарга иртәрәктер,
Исемнәрне ташка уеп.

## КИРӘК ТҮГЕЛ УРТАГЫ

Һәркемнең дә үз тормышы,
Үзгә токкан кыйбласы.
Дөрес микән тоткан юллар –
Булыр туктап уйласы.

Үтә айлар, үтә еллар,
Кырау төшә чигәгә.
Кайталмыйбыз вакыт табып
Кайчак туган өйгә дә.

Әллә тормыш безне куа,
Әллә безме – тормышны?
Шатланабыз һәр яз саен,
Чыктык, диеп, бу кышны.

Гомер бирсәң, саулыгын бир,
Сөю бирсәң – назларын.
Артыгына өмет тотмыйм,
Бир син миңа язганын!

Әйләнә дә кайта кышлар,
Төшкән карның кырпагы.
Бир син миңа үземнекен,
Кирәк түгел уртагы.

## ҖИЛӘКЛЕ АЛАН

Җәйнең эссе көнендә,
Җиләк пешкән чемендә.
Өзеп бирим дигән идем –
Юк янымда кемем дә.

Җиләкләре охшап тора
Синең алсу битеңә.
Сиңа чемләп җиләк җыйдым
Таныш алан читендә.

И бу җәйнең кичләре,
Пешкән җиләк исләре!
Син булмагач янәшәмдә,
Җаным әллә нишләде.

Җил иркәли тәннәрне,
Оныттырып гамьнәрне,
Алып кайтам иренемдә
Сиңа җиләк тәмнәре.

Быел җәйләр җиләкле,
Тиз тутырдым чиләкне.
Аяк-куллар җиләк төсле –
Биргән черки кирәкне!

## АҢЛАМЫЙЛАР ШУҢА БЕЗНЕ

Кемнәр җирдә эшләмәгән,
Татымаган тир тәмен –
Шулар белми бу дөньяда
Яшәүнең дә чын ямен.

Агач утырт, өй сал башта,
Эшләп кара кул белән.
Сез эшләргә тумаган шул,
Алдырасыз тел белән.

Хезмәт түгел, ә зур байлык
Күтәрде күбегезне.
Тир түкмәгән, бил бөкмәгән
Ничек аңласын безне?!

Депутатныкы – депутат,
Түрә баласы – түрә.
Шуңа да сезгә хөрмәт аз
(Кеше бит барсын күрә).

Яшәү ямен, ипи тәмен
Белер иде эшләсә.
Кеше хәлен кеше белми,
Үз башына төшмәсә.

## СЫНАЛДЫК

Очраштык без синең белән
Тауның тар сукмагында.
Карап тордың озак кына
Каршыма тукталдың да.

Мин уйладым аңлар дип,
Син уйлаган җанвар дип.
Ә бит юкса икебез дә
Бер гөнаһсыз җаннар бит.

Үтеп кара тар сукмактан,
Бер-береңә кагылмый!

Яшьлекнең бу вакыйгасын
Мөмкин түгел сагынмый.

Чынлап булмас, ялгыштыр
Тиде кулың кулыма.
Ходай безне сынар өчен
Чыгарган тау юлына.

Без инде сыналганбыз,
Сагышка уралмабыз.
Тар сукмактан юлга чыктык,
Моннан соң югалмабыз.

## БЕЗНЕҢ ИНЕШ

Безнең өчен иң зур елга
Ул басмалы инеш иде.
Бае да юк, ярлысы да –
Барчабыз да бер иш иде.

Безнең өчен иң зур диңгез
Инештәге буа иде.
Җәй буена һәммәбезне
Араламый юа иде.

Су буена төшәм дисәк,
Әти-әни тыймый иде.
Җәй җиттеме, шул ук инеш
Балык белән сыйлый иде.

Буа буар көннәр җитсә,
Авылда ямь арта иде.
Кеп-кечкенә инеш суы
Әле он да тарта иде.

Ул чактагы авылдашлар,
Ахры, бераз «исәр» иде:
Читтән кайткан иң беренче
Су буена төшәр иде.

Шул буада һәр баласы
Балык кебек йөзәр иде.
Буа да юк, тегермән дә –
Авыл ничек түзәр инде?
Шул вакытлар, искә төшеп,
Үзәкләрне өзәр инде.

## АҢЛАМЫЙ

Чәчәкләрдән бал тамган чак –
Җирдә җылы июль ае.
Ял итәм дип «җәфа чигә»
Чит илләрдә урыс бае.

Ни кылса да үз иркендә,
Без кушмаган, аның уе.
Кояш көлгән мондый көнне

Иң яхшысы – Кама буе.

Ял итәргә менә дигән
Бу елганың комлы яры,
Ә читтәрәк чип-чиста күл,
Каплап тора таллык бары.

Нигә миңа чит илнеке –
Өстәлемдә бакчам сые.
Якын күрдем шушы җирне,
Үземнекен гомер буе.

Безгә дә бер чыгар иде,
Теләк булса, бару җае.
Җәннәт юкса туган җирләр,
Тик аңламый урыс бае.

## МИНЕМ КЕБЕК

Миңа булган карашыңны
Никләргә дип сорадым?
Ишетмәгән булса икән
Җавабыңны колагым.

Аксын, диеп, сагышларым,
Су буйларын урадым.
Аптырагач, мин Ходайдан
«Кавыштыр» дип сорадым.

Болай авыр булмас иде,
Нишләдем мин, нишләдем?
Күкнең җиденче катыннан
Егылдылар хисләрем.

Авыр булса да аңладым
Бүген сине җуйганны.
Белмим ничек дәваларга
Кан саркыган бу җанны?!

Син төшердең шушы хәлгә,
Очтым тирән упкынга.
Бәлки, син дә югалтырсың,
Әмма миндәй юксынма.

## МОҢАЮ

Ник моңая соң бу күңел?
Гомерләр үткәнгәме?
Алда безне билгесезлек
Сагаеп көткәнгәме?

Бетеп тормый икән нигә
Күңелнең боек мәле?
Без яшәргә туган җаннар,
Күңелкәй, боекма әле!

Безне көткән алсу таңнар
Атачак әле тагын.
Уфтанма уйлап үткәнне,
Син аны бары сагын!

## ЙА РАББЫМ

Горур булсаң горур булдың,
Тик үземә караттым.
Гомерлеккә була күрсен
Сайлаганым, йа Раббым.

Ятлар янда чуалса да,
Бары сине яраттым.
Шундый бәхет бирсәң икән
Һәрберсенә, йа Раббым.

Тап төшмәде мәхәббәткә,
Юа тордың, агарттың.
Азаккача шундый булсын
Моннан соң да, йа Раббым.

## ҮЗЕМНЕКЕ ҮЗӘКТӘ

Берәүләрнеке – Айзирәк,
Берәүнеке – Гөлҗиһан.
Югалтсаң, табармын димә,
Бигерәк зур бу җиһан.

Күпме шигырь багышлаган
Берсе Айсылуына.
Мин шатланып туя алмыйм
Җирдә син булуына.

Кичләр җитсә күтә кемдер,
Айга карап, Айнурын.
Миңа Ходай җирдә бирде
Мәхәббәтнең иң зурын.

Берсе Чулпанын сагына,
Берсе эзли Йолдызын.
Эзләмәдем мин күкләрдән,
Сөйдем гади җир кызын.

Исеме дә гади аның,
Җир гөле ул Гөлсинә.
Җирдә үскән шушы гөлне
Алыштырмыйм берсенә.

## АГАЛАР

Ага болыт бер карусыз,
Ага җил уңаена.
Аккан болыт – узган еллар,
Шуңамы моңаела.

Бер офыктан бер офыкка
Агалар, күкне иңләп.
Сәламнәре булды, ахры,
Алды бер иртән җилләп.

Өстә – болыт, аста – елга,
Тавышсыз агышлары.
Бушап калган бу җанымда
Бер төркем сагыш бары.

Хәлне дә сорамыйлар,
Куллар да болгамыйлар.
Иптәш тә юк сөйләшергә,
Ә башта күпме уйлар...

Җиңелдер җил уңаена,
Тик иярмим агымга.
Дәвам итәм үз юлымны,
Тәнемдә көч барында.

## ЗАМАН ЧИРЕ

Кибет яны. Яшь кыз бала.
Авызында – сигарет.
Ясамаганнардыр аны,
Сеңлем, һич тә сиңа дип.

Авызында – сигареты,
Кулларында – сырасы.
Килә дә бит дәшеп алып
Колагыңны борасы...

Заманы шул башка хәзер,
Законы бар, ярамый.
Ә әйтүнең файдасы юк,
Борылып та карамый.

Бер кулында – яшь баласы,
Бер кулында – сигарет.
Сигаретын тоткан көе
Ил алдына чыккан бит...

## КИРӘКТЕР

Карт тирәктә кара карга
Иртәдән үк «кар» да «кар».
Аңлый алмыйм бу тавышны,
Әллә сагыш, әллә зар.

Каргаларны файдасыз дип,
Белмим, кайсы тараткан.
Аларны да, безнең кебек,
Җиргә Ходай яраткан.

Ашаса да вакыт-вакыт
Урлап тавык ярмасын,

Юк, кирәкмәс димәс идем
Мин җирнең бу каргасын.

Һәрберсенең үз урыны,
Карганыкы – тирәктер.
Кайчак безгә алар кебек
Кычкырырга кирәктер.

Яшәп була арбасыз,
Торып була ярмасыз.
Бик күңелсез булыр иде
Әмма ләкин каргасыз.

## БҮРЕ ЙӨРИ, ЭТ ӨРӘ

Чиста куллылары сирәк,
Юк урламаган түрә.
Ни кырасың каршы чыгып,
Ә бит барсы да күрә.

Урлаган маллары белән
Хет стенага терә!
Алган «җәзаларын» белгәч,
Башта чәч үрә тора.

Аптырагач, әйтә халык
Мәкаль белән үз сүзен:
«Чукымыйдыр безнең илдә
Козгыннар козгын күзен».

Законы шул аларныкы,
Әйтмәгән халык зерә:
«Бүреләр гел үз юлында,
Эт кенә юкка өрә».

## ГҮЗӘЛЛӘР БӘЙГЕСЕНДӘ

Красотою мир спасётся.
*Ф. М. Достоевский*

Җиңүчегә бүләк дисәк,
Байлар тормый акчадан.
Башладылар быелгысын
Хәтта ясле-бакчадан.
Оештыра үз бәйгесен
Һәр оешма, һәр колхоз.
Бәйге бара ил буенча,
Ел әйләнә, бер ялсыз.
Иң гүзәлен сайлый байлар,
Китереп бөтен шартын:
Бөтерелә чибәр кызлар,
Күрсәтеп алдын-артын.
Йә чишенеп уза алар,
Йә киенеп үтәләр.
Ә залдагы ир-ат халкы

Туктаусыз аһ итәләр.
Бу күренеш охшый бара
Инде заман чиренә.
Җиңүчегә шәп машина,
Затлы туннар бирелә.
Бу – кемгәдер күңел ачу,
Тик хыянәт – халкыма.
Күпме кеше эшләп йөри
Бары тамак хакына.
Заманасы башка хәзер,
Без шул инде үзгәрдек.
Болай барса, җиңалмастыр
Бу дөньяны гүзәллек.

## ХУШЛАШУ

Бар туганнар җыелган чак.
Каберенә туфрак салам.
Үксеп елый сабый сыман
Алтмыш яшьлек ятим балаң.

Зират юлы. Авылдашлар.
Төшеп киләм башны иеп.
Хәзер кемгә дәшим инде,
Өйгә кергәч, «әни» диеп?!

Керфекләргә яшь эленгән,
Әмма кайгы җиңә алмый.
Йөрер инде хәзер шулай
Бертуктаусыз арттан калмый.

Дөньясында авыр тынлык,
Кояш байый җилсез генә.
Тәүге тапкыр төнгә керә
Бүген җиһан синсез генә.

Син тормышка гашыйк идең,
Аз таммады монда тирең.
Тел ачкычы бирсен Ходай,
Мамык булсын яткан җирең!

## БУЛАЛМАМДЫР ФӘРЕШТӘ

Борчак төшкән ак күлмәгең
И ятышлы иңеңә.
Итәге дә тез турыннан,
Таман гына җиңе дә.

Аягыңда туфли түгел,
Ә зәңгәр сандалидыр.
Карашыңны тоткан ир-ат
Күз кысып алгалыйдыр.

Килешле ак иңнәреңә
Яткан чәчең таралып.
Ахры, күңел дигәнендә
Килә сөю яралып.

Бик тә тәңгәл бит сыныңа
Чак кына горур башың.
Тел тидермим керфегеңә,
Чәчеңнән кара кашың.

Тартылам шул гүзәллеккә,
Синдәй җирдә бер генә.
Юк, фәрештә булалмамдыр,
Кайчак күңел сөрлегә.

* * *

*Роберт Миңнуллинга*

Тормышта да, шигырьдә дә
Гадәтенчә тыйнак кына.
Соравыңа җавап бирер
Ашыкмыйча, уйлап кына.

Шигырьләре җырлап тора,
Яза төсле уйнап кына.
Озын түгел, кыска түгел,
Коеп куйган, җыйнак кына.

Әмма талант дигәннәре
Күберәктер, белмим, кемдә?!
Нигә шундый була икән
Миңнуллиннар һәммәсе дә?

## ӘБИЛӘР ЧУАГЫ

Кояш чыкты сагындырып,
Нур иңде күкләренә.
Урала җирдә һәммәсе
Пәрәвез җепләренә.

Чыпчыклар концерт бирәләр
Гөлҗимеш куагында.
Ел да шундый бер көн була
Әбиләр чуагында.

Әби-бабай җылы җыя
Суынган тәннәренә.
И тырыша кояшы да,
Кергәндәй хәлләренә.
Көне шундый булгангамы,
Тәме арткан чәйләрнең.
Җирдә әбиләр чуагы –
Кайтавазы җәйләрнең.

## СЕЗНЕ ЖӘЛЛӘП

Ни көн дими, ни төн дими,

Күктә болыт яңгыр или.
Мондый көнне гел юктан да
Күңелләрне сагыш били.

Зонд астына кача-кача,
Суларына баса-баса,
Эшкә барам көн дә иртән
Елап торган урман аша.

Яратмый ул кызганганны,
Җәлләп кулын сузганнарны.
Карап кала моңсу гына
Машинада узганнарны.

Киенә алмый җылы итеп,
Без әйткәнне аңласа да.
Табигатьтә гел киресе:
Без киябез, урман сала.

Җылытасы иде дә бит
Алып сезне кочакларга,
Тик җылына агачларың
Миләш яккан учакларда.

## АЛМА КОЕЛГАН ЧАКЛАР

Дөнья суда коена,
Җанга сагыш уела.
Көз җиткәнен шуннан беләм –
Җиргә алма коела.

Җәйгә нокта куела,
Шуңа алма коела.
Рәхим итегез, туганнар,
Көзге бакчам сыена!

Бакчам керде көзенә,
Көн дә алма өзелә.
Күзем төште көтмәгәндә
Алма кебек тезеңә.

Очкынланды күзләрем,
Онытылды сүзләрем.
Ашап туймас алмам, диеп
Иркәләдем үзләрен.

Көн-төн алма коела,
Бүләк кемнәр туена?
Тик минем күз төшкәненә
Кагылмагыз, тыела!

## БЕЗ ШУЛ

Каеннар тора тирбәлеп,
Имәннәр ала шаулап.
Йөрмиләр юкка кычкырып,

Безнең күк ирек даулап.

Шомыртлар җиргә иелгән,
Колмак үскән уралып.
Бирделәрме соң ирекне,
Ә бит азмы сорадык?!

Бөгелгәнне гел бөгәләр,
Бөгә алмыйлар зирекне.
Сынса сына, баш бирми ул
Яратканга ирекне.

Юк, язмадым бу юлларны
Үрнәк ал, дип, зиректән.
Без шул җирдән аерылдык,
Алар – җиргә береккән.

## ҮПКӘМ ЮК

Тормыш шактый иләде,
Әмма кайгы өймәде.
Без үтмәслек түгел иде,
Вак булса да иләге.

Тормыш шактый сынады,
«Авырмы?» – дип сорады.
Бик яшисе килә иде,
Сер бирмәдек шуңамы.

Тормыш шактый кыйнады,
Түзалмас дип уйлады.
Үҗәтләнеп баш бирмәгәч,
Шатлык белән сыйлады.

Нишләр идең, кара кайгы
Килеп какса капкаңны?
Юк, аерым какмады,
Ахры, безне яклады.

Тешне кыссак кыса идек,
Тик күздән яшь акмады.
Ахры, безне ялгыш юлдан
Алла үзе саклады.

## АҢЛАСЫННАР ИДЕ

Нинди серле тыюлык бу?
Коймалары яшелдән.
Эченә күз салыйм әле,
Бу койма ни яшергән?

Ачыкларга исәп барсын,
Хәл кылам уйлаганны.
Күрдем койма ярыгыннан
Балыклар уйнаганны.

Курыкмасын балыклары,
Күпме кирәк уйнасын.
Китеп бардым кабат ябып
Күлнең яшел коймасын.

Кыштырдады камыш-койма,
Ябылды күл-күзгә дә.
Аңласыннар иде шулай
Кирәк чакта безне дә.

## ТҮБӘН КАМА

Ләйсән яңгыр явып узган –
Түбәләрдән тамчы тама.
Яшь кызлардай күкрәк ачкан
Җылы язга Түбән Кама.

Язгы җилгә күкрәк куеп
Атлый шәһәр алга таба.
Чулман ташый, яры тулган,
Дулкыннары ярга кага.

Ашкындырып, язлар килә,
Ашыктырып, вакыт чаба.
Бәхетсез дип йөргәннәр дә
Сиңа килеп бәхет таба.

Син үзең дә язга тартым –
Барсы гүзәл, барсы яңа.
Якты булсын язмышың да,
Ак шәһәрем, Түбән Кама!

## ЯШӘҮ – КӨРӘШ

Көз кереште үз эшенә,
Башлады явымнарны.
Сынавы инде быел да
Ныклыкка авылларны.

Юллар өзелде кибеткә,
Урамнар батты сазга.
Җәннәт инде су кошлары –
Үрдәкләр белән казга.

Аякларда – резин итек,
Кулларда – тимер көрәк.
Бәрәңге ала күбесе,
Аягын көчкә сөйрәп.

Коеп яуган бу яңгырда
Кем көтүгә мал куар?
Ашарга сорый кычкырып
Өйдә калган мал-туар.

Җаны барга азык кирәк,
Ни хәл итәсең бирми?

Китәселәр китә тора –
Авыл кемнедер җирли.

Исәннәргә хат ташучы
Пенсиясен өләшә.
Көз җиттеме, авыл шулай
Яшәү өчен көрәшә.

## БАР ӨМЕТЕМ ЯЗЛАРДА

Салкын зыян салмагандыр,
Исән-имин торамсыз.
Сәер булды быелгы кыш,
Узды-китте бурансыз.

Торып-торып уйландыра,
Гаҗәпләнәм бу кышка.
Уздырды күк үз вакытын
Бер файдасыз, гел бушка.

Кул селтәдем кышларына,
Бар өметем язларда.
Вакыт җитте туңган җирне
Җылы бөркеп назларга.

Яз язлыгын итми калмас,
Шулай булыр, ышанам.
Нинди яз ул, ташкын булып
Чыкмаса тар кысадан.

Көлә кояш, шатлыгы зур,
Күз чагыла ак нурдан.
Изү ачып яз каршылый,
Тау шул безне уздырган!

## ӘЛЕ ЯРЫЙ ӘЙЛӘНӘ

Кояш җиргә күз ташлады,
Ачып болыт итәген.
Беләбез бит елак көзнең
Тиздән ташлап китәсен.

Туктала да безнең турга
Түгә болыт чиләген.
Белмим инде, кемгә генә
Калды икән кирәгең?

Түзәргә икән түзәрбез,
Түзми ни хәл итәсең?
Беләбез ич көз артыннан
Салкын кышлар киләсен.

Кышы язга бәйләнә,
Язы җәйгә бәйләнә.
Нишләр идек, җир туктаса,
Ярый әле әйләнә.

## ТАПТЫК

Тормыш юллары бормалы,
Безне кая бормады.
Акыл алдан йөргәнгәдер,
Зурдан ялгыштырмады.

Өйләндерде әти-әни
Хәлдән килгәнчә, туйлап.
Бозмый хәер-фатиханы,
Киләбез гомер буйлап.

Әтисе малаен кыйный,
Мин торам шуны уйлап:
Булмаса әгәр башында,
Кертермен димә кыйнап.

Булмый балачакны сузып,
Йөрермен димә уйнап.
Тормыш итәр вакыт җитәр
Башыңа акыл җыйнап.

Белмим, кайсын үз итәрсең,
Җирдә юллар, һай, күптер.
Без менә безгә кирәген
Таптык, Аллага шөкер.

* * *

Күңел аклыгы кердә,
Элә аласың түргә.
Булалмабыз болай чиста
Кергәндә генә гүргә.

* * *

Кергәч кеше көзенә,
Борылып карый эзенә.
Үземдә дә шундый халәт,
Ышаныгыз сүземә.

* * *

Чебен ябышкан балга,
Сандугач кунган талга.
Ә бер салмыш, салган саен,
Хис итә үзен ялда.

* * *

Яшел газон, сары яфрак,
Яшел җирлек, сары тап...
Җәй дип бәхәсләшер идең,
Ни эшлисең, бар да хак.

## ОНЫТКАНМЫН ӘДӘПНЕ

Сөйләшенгән вакыт узды,
Инде шактый кичектең.
Ватылмагандыр бит юкса
Кыңгыравы ишекнең?

Төгәл беләм, сәбәп башка,
Ишектә түгел гаеп.
Каршылый алмадым тагын
Үзеңне колач җәеп.

Сәгатьләр дә ялгышмаган,
Гаепләргә сәгатьне.
Үзебездән эзләү кирәк
Мондый чакта сәбәпне.

Син бит бүгенгеләр түгел
Санламаска әдәпне.
Кыз янына егет бара –
Онытканмын гадәтне.

## ГАРАСАТ

Асты өскә килде бугай,
Узды җирдән гарасат.
Айлар, еллар кирәк булыр,
Бар зыянны санасак.

Кайсы ауган, кайсы купкан,
Кайсы сынган төбеннән.
Җирдә күпме бәхетсезләр
Пәйда булды бүгеннән.

Булды бар да күз йомганчы,
Кыска гына мизгелдә.
Зыян күрми калмагандыр
Бер гөнаһсыз изгең дә.

Кара болыт кыяларын
Куды яшен камчылап.
Коеп явар дигән идем,
Узды бары тамчылап.

Таулар авыр сулады,
Урманда җил улады.
Ә көчлеләр, җирне кочып,
Көчсезлектән елады.

## ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ

Ике тапкыр артачак, ди,
Пенсияләр биш елдан.
Баеп бетәчәкбез икән,
Барсак әгәр бу юлдан.

Бәлки, исән калыр идек,
Җитсә әгәр җылы яз.
Ярлы халык баеганны
Күрәм дисәң, өмет аз.

Артыгына өмет итмим,
Түзеп булса быелга.
Бәяләр бит ике тапкыр
Арта хәзер бер елда.

Бер дистәсе кырык тәңкә.
(Белмим, кем генә ала?)
Хәзер дәүләт тавыгы да
Алтын йомырка сала.

Астагылар зар елыйлар,
Өстәгеләр – урлаша.
Ярлыларга булышам дип,
Дәүләт хәер сораша.

## ТАБЫШМАКЛАР

* * *

Икесе дә эшсезләр,
Икесе дә тешсезләр.
Тагын уртак сыйфатлары:
Икесе дә көчсезләр.
Берсе гел күккә карар,
Берсе үткәнен санар.
Ә шулай да бер-беренә
Юаныч әле алар.

*(Әби белән бәби)*

* * *

Гомер буе үзгәрешсез,
Чишенми дә, киенми дә.
Яз килгәнне сәбәп итеп,
Алай артык сөенми дә.

Үсә-үсә үзгәрми ул,
Ничек булса, шулай кала.
Күңелендә шатлык йөртә
Аны күргән һәрбер бала.

*(Чыршы)*

## ИНЕШ БУЕНДА

Саклап олы дәрәҗәсен
Төзәтенгән, бизәнгән.
Бормаланып, ашыкмыйча
Агып килә үзәннән.

Ярларында тал да зирек,
Болыннар тирә-ягы.
Җилләрнең чәчәк исеннән
Исереп йөргән чагы.

Су коена бала-чага
Тугайларда көн буе.
Күбәләкләр бии янда,
Таллыкларда – кош туе.

Таң тудымы, малай-шалай
Ярдан балык каптыра.
Ә кармагы булмаганнар
Аны бездән таптыра.

Гөжләп тора инеш буе,
Үз эшендә һәммәсе.
Күктә – җылы җәй кояшы,
Җирдә – үлән җәймәсе.

## ТУГАН ЯККА МӘДХИЯ

Тауга карап тау булмабыз,
Без үзәндә үскәннәр.
Әрәмәдә балан яна,
Бөрлегәннәр пешкәннәр.

Үз янына дәшсә дә тау
Кешеләрнең беришен,
Безнең төшкә болын керер,
Сагынырбыз инешен.

Оныттыра алмас таулар
Туган якны ничек тә.
Омтылсак та гел биеккә,
Без үскән талбишектә.

Туган нигез болдырында
Уйланып тордым иртән.
Ни диярсез, авылдашлар,
Мин шулай фикер йөртәм.

Шуңадырмы якын миңа
Үрләрнең дә сөзәге.
Мин туган җир минем өчен
Бу дөньяның үзәге.

## КӨЗГЕ УРМАН

Һәрбер төбе ятак сыман:
Чуар юрган, сары мендәр.
Йокларгамы, кышларгамы,
Урын җәйгән монда кемнәр?

Күзе булган күрми калмас,
Җаны булган нидер тояр.

Уйга калган куакларда
Ямансулый күпме оя.

Каян килә бу ят тавыш?
Йә җәнлектер, йә бер коштыр.
Җәнлек түгел, ә җил йөри,
Яфрак җыеп кыштыр-кыштыр.

Агачлары шул булса да,
Урман башка, киткән яме.
Чишмә генә челтер-челтер,
Юк бернидә аның гаме.

Дәва эзлим җаннарыма,
Нигә миңа агач саны?
Җанга дәва бирер булса,
Көз димәсләр иде аны.

## БОРЧЫЛЫП

Әллә нигә уйга кердең,
Уйлап йөрим сине һаман.
И кыендыр ялгызыңа,
Ир белән дә авыр заман.

Шунсы яхшы: зарланмыйсың,
Balаңны да үстерәсең.
Син ана да, син ата да,
Икеләтә көч түгәсең.

Берәү булса елар иде,
Гаҗәбе шул – зарланмадың.
Булгандыр бит сүз кушучы,
Тик син генә парланмадың.

Сере бардыр сыман моның –
Мине шунсы кызыктыра.
Ага вакыт сулар кебек,
Гомерләр дә уза тора.

Ирле итеп, парлы итеп
Килә сине күрәсем бер.
Минем башка ниләр килмәс,
Анысын үзең беләсеңдер...

## КИРЕ КАЙТМЫЙ

Көз җитсә, кошлар китә,
Яз җитсә, бозлар китә.
Һәркайсының үз вакыты,
Яшь кызлар кияү көтә.

Бер урында тыныч кына
Яшәүләргә ни җитә?
Ә кемнәрдер гомер буе
Йөриләр кайта-китә.

Төшенәбез һәммәсенә,
Гомерләр итә-итә.
Гөрләшеп яшәр чакларда
Кайтмаска дуслар китә.

Кими бара якыннарың,
Кими җирдә таяныч.
Кайтмый бары һәр киткән дә –
Шунысы иң зур аяныч.

## ДӨРЕСМЕ?

Туганнар түгел берсе дә
Туганнар каберендә.
Баш салганнар буйсынып тик
Кемнеңдер әмеренә.

Уртак колхоз, уртак байлык
Үткәндер бәгыренә.
Язмыш шаярулрымы –
Уртак бит кабере дә.

Барсы уртак булган илдә
Уртактыр кадерең дә.
Һәммәсенә олы бер таш
Туганнар каберендә.

Исемнәрен дә белмибез,
Динен дә, Тәңрен дә.
Елый җаннар, дога көтеп,
Туганнар каберендә.

## * * *

*Гүзәл белән Рамилгә*

Рамиле монда икән,
Кайсы була Гүзәле?
Рифкать абый, диләр мине –
Таныш түгел без әле.

Син бүгеннән безнең туган,
Сеңлем, куркып карама.
Иң яратканыбыз булып
Яшә безнең арада.

Егетебез – ир солтаны,
Сүзен очырмый җилгә.
Тормыш диңгезен кичкәндә,
Син иптәш бул Рамилгә.

Алда сезне юллар көтә,
Юлдаш булсын пар канат.
Яшьлегемне искә алдым
Бүген мин, сезгә карап.

Сезнең белән табын якты,
Сезнең белән и рәхәт.
Озата барсын артыгыздан
Һәрчак чиста мәхәббәт.

## ШУЛАЙ ЯЗГАН

Су өстендә томан дисәм,
Ул бит бары пар икән.
Бу дөньяда без белмәгән
Әллә ниләр бар икән.

Басма дигәч кергән идем,
Бигрәкләр дә тар икән.
Монсы әле башы гына,
Алда ниләр бар икән?

Минеке дип йөри идем,
Ә ул уртак яр икән.
Кемгә кирәк уртак бәхет?
Күрәселәр бар икән...

Кичтән яңгыр ява иде,
Иртән торсам – кар өйгән.
Йөр син менә октябрь дип,
Күрәселәр бар икән!

Әле кырда эш бетмәгән,
Кем яудырган – күрәсен.
Алла безгә шулай язгач,
Кем күрсен без күрәсен?!

## КЫЮСЫЗ КЫЗ

Өй артында кар шыгырдый.
Болай соңлап кем йөри?
Кыз янына егет килгән,
Эте дә шуңа өрми.

Бөтерелә өйдә кызым,
Кыймый миннән сорарга.
Каршы килмәс идем дә бит,
Чыгам, дисә, урамга.

Вакыт уза, урамда кыш.
Ул ояла, мин көтәм.
Берәү булса, сәбәп табып,
Ычкыныр иде күптән.

Үзем кебек кыюсыз шул,
Үзем кебек бик тыйнак.
Түзмәдем, әйттем үзенә,
Кыюлыгымны җыйнап:

– Талчykканга охшагансың,
Бар, – дидем, – һава сула.

Бу салкында кар дигәнен
Күпме таптарга була?..

## МӘХӘББӘТ

Мәхәббәт ул – олы дөнья,
Булмый аны кисәкләп.
Һәм шуңа да куялмыйсың
Алдан барсын исәпләп.

Мәхәббәт ул – серле дөнья,
Бетердем димә аңлап.
Килеп кабалар тозакка
Йөргәннәр дә гел алдап.

Мәхәббәт ул – гаҗәп дөнья,
Юк коймасы, юк чиге.
Йөрәктә аның ачкычы,
Йөрәктә аның биге.

Мәхәббәт ул – чиксез дәрья,
Кичәсең гомер буе.
Йә идеаль тәртип анда,
Йә уйный пәри туе.

Мәхәббәт ул – кара урман,
Куркып калма, ярамый.
Сөйләп берни аңламассың,
Үзең кереп карамый.

## ВАКЫТ ӘЙТЕР

Гомер – баскыч, ә без – юлчы.
Менәбез дә менәбез.
Алда гомер басмалары –
Безгә ак юл теләгез!

Әле безнең менгән вакыт,
Уйлаган юк төшәсен.
Кесә җанлы булганнары
Калынайта кесәсен.

Киңәя офыклары да,
Яктыра менгән саен.
Берәүләре йолдыз чүпли,
Тапканнар, димәк, җаен.

Гайбәт сата бер тинтәге,
Кайсыдыр акыл жыя.
Башлы-күзле булганнар күп,
Күбесе корган оя.

Төшәр вакыт житкән мәллә,
Барлый һәркем үз малын.
Шагыйрь барсын шигырь иткән,
Бу бик тә үзгә алым.

Тирәнме җирдә эзең,
Булырмы җылы көзең?
Килер бер көн, чын хөкемдар –
Вакыт әйтер үз сүзен.

## ИҢ-ИҢЕ

«Иң җылы җир кайда?» – дисәм,
Белмисез пычагым да.
Җирдәге җәннәт дигәне
Ул – кызлар кочагында.

«Иң салкын җир кайда?» – дисәм,
Син никтер уйчан гына:
«Ул, – диден, – син яратмаган
Хатын-кыз кочагында».

«Иң кайнар җир кайда икән?» –
Белмисез пычагым да.
Ул – синең янган мизгелең
Мәхәббәт учагында.

## ВАКЫТ – ЕЛГА

Вакыт – елга, кеше – юлда,
Сизми гомер агышын.
Җитми кайчак гомере дә
Төзәтергә ялгышын.

Вакыт – елга, айлар – мизгел,
Көннәр бары чагылыш.
Телә җанны гомер буе
Үткәндәге бер ялгыш.

Ага вакыт елгалары,
Юа гомер ярларын.
Җилләр, безгә булышкандай,
Кага чигә карларын.

Ага вакыт, туктар димә,
Охшаган ул ташкынга.
Яшәгәндә көрәшербез,
Исән булсын баш кына.

Вакыт – елга, кеше – юлда,
Язмасын һич туктарга.
Гомер бер бит, ни эшләрсең
Әрәм итсәң юк-барга?

## БУЛЫР МИКӘН?

Тоткасы юк чиләкнең,
Төбе тишек иләкнең.
Белмим ничек җиткерергә –
Бетәсе юк кирәкнең.

Кибет тулы әйбер хәзер,
Эзе дә юк чиратның.
Түлә дә ал, түлә дә ал,
Эше бетте ир-атның.

Алыр идек аны без дә,
Юк шул менә түләргә.
Күрәм, сезнең авыз ерык,
Тотынасыз көләргә.

Алда әле хезмәт хакын
Тагын бер ай көтәсе.
Булыр микән бу кирәкнең
Кайчан да бер бетәсе?

## УЙЛАГАНЧЫ

Дулкын уза тәнем буйлап,
Ялгыш кулың тисә дә.
Йөрәгемнең көчәнеше
Җитә микән ничәгә?

«Сакланганны саклыйм, дигән,
Ток сукмасын, кагылма!» –
Кисәтәләр иде мине
Шулай балачагымда.

Балачаклар күптән узган,
Ир уртасы яшендә.
Шуны сорыйм: «Курыктыңмы?
Йә, әйт әле, яшермә!»

Сөю тулы күзләреңнән
Гүя очкын чәчелә.
«Ни булыр?» дип уйлаганчы,
Кулым тиде чәчеңә...

## ШУНДЫЙЛАР ДА БУЛГАЛЫЙ

Булмаса да үз әйбере
Карар өчен кулга тотып,
Карап тора синекенә,
Җирәнгәндәй, чырай сытып.

Аңлатасы иде дә бит
Якасыннан шәпләп тотып,
Тик мин әле түзеп торам,

Ачуымны эчкә йотып.

Китеп барды тып-тын гына,
Әллә инде шуны тоеп.
Эчтәгесе йөзгә чыга,
Уең булса әгәр кыек.

## БОРЧЫЛМАГЫЗ

Чишмәләрнең суы арткан,
Тулып ага улагы.
Җылы көзләр – ерак үткән,
Җитте көзнең елагы.

Соңарганбыз сокланырга,
Узган инде алтыны.
Иртә-кичен кырау төшә,
Сизелә кыш салкыны.

Борчымасын җаныгызны
Билгесезлек газабы.
Фасыл алышынган вакыт –
Бүген көзнең азагы.

## КАЙСЫГЫЗ БЕЛӘ?

«Күпме генә уйласам да,
Чишә алмыйм бер серне –
Эчкән сулары да бер үк,
Җимешләре ник төрле?

Берсе – ачы, берсе – баллы,
Үссәләр дә бер җирдә.
Белмисезме нигә шулай?» –
Сорау бирдем бер иргә.

Бер гаилә, ике бала,
Икесе ике төрле.
Соравы бар, җавап көтәм,
Кайсыгыз белә серне?

## КОЯШ ТУРЫНДА ҖЫР

Кояш йөзә күктә дә,
Кояш йөзә күлдә дә.
Кояш кирәк безгә дә,
Кояш кирәк сезгә дә.
Кояш кирәк чүлгә дә,
Файдалы ул кемгә дә.
Кояш көлә көзен дә,
Тора, димәк, сүзендә.
Кояш көлә кышын да...
Туктап торыйк шушында.
Кояш көлсен, дөрләсен,
Иртән күккә үрләсен.
Кичен баеса да ярый,
Әмма бер дә сүнмәсен!

## ЯЗГЫ УЯНУ

Мондый хәлне кем күргән –
Кояш җанга нур элгән.
Яз җиттеме, күзен ача,
Терелә көзен үлгән.

Ботак саен бөреләр,
Түп-түгәрәк, эреләр.
Тулышканнар җылы нурга,
Димәк, бар да тереләр.

Бу уяну, бу үзгәреш
Кояш белән җирдәндер.
Үлән борын төрткән җиргә
Ятып ауныйм ел да бер.

Уянган җир куеныннан
Куәт алам тәнемә.
Тиздән барсы төренәчәк
Язның яшел шәленә.

«Җылы – миннән, суы – синнән!» –
Кояш Җиргә боера.
Карурманда соңгы булып
Яфрак яра туера.

Хыял – чиста, күңел – пакь,
Барсы исән, барсы шат.
Кавышырга кулай вакыт,
Кайтам сине каршылап.

## ҮЗЕМ ТУРЫНДА

Байларны зурламадым,
Ярлыны хурламадым.
Үзем дә, баерга теләп,
Ятныкын урламадым.

Начар булса да үземә,
Кешене алдамадым.
Яшь чагында чама белеп
Әз генә салгаладым.

Кемнәр генә сөйләсә дә,
Буш сүзне тыңламадым.
Барырмын, дип әйткән җиргә
Булмады соңлаганым.

Тик ияреп киталмадым
Бу чорның агышына.
Бише белән түләтәләр
Шуңа һәр ялгышыма.

Бай ярлыны аңламый шул,
Ваемсыз ул тук күңел.

Дошманнарым бардыр димим,
Ә дусларым юк түгел.

Ни язсам да күздә тотам
Һәрчак туган ягымны.
Барыбер дә күптер анда
Аңлаучылар җанымны.

# Таң яктысы

## МИН РӘХМӘТЛЕ

Офыкларда таң яктысы,
Керфек кага тау иле.
Уза яннан, сәлам биреп,
Соңга калган таң җиле.

Бер гаҗәеп манзара бу,
Карап торам онытылып:
Кояш күккә күтәрелә,
Кыя тауга тотынып.

Кояш – юлчы, җылы сибә,
Йөге шактый бушаган.
Авыр булган, ахры, көне,
Талчыкканга охшаган.

Кич җиткәнен шуннан белдем:
Сигезенче яртыда
Төшеп ятты арган кояш
Безнең урман артына.

Бер үпкәм юк бу кояшка,
Чыгарса да еш тирне.
Шундый булырга кирәктер,
Җылытам дисәң җирне.

## АҢЛАШЫЛА

Елга булгач, сусыз булмый,
Булмый тагы ярсыз да.
Ә кешегә пары кирәк,
Авыр җирдә парсыз да.

«Тамагым тук, өстем бөтен,
Яшим, – дисең, – ансыз да».
Ялгышасың, җаны барга
Кыен, дускай, назсыз да.

Яшәп була безсез дә,
Тормыш бара сезсез дә.
Кемгә нәрсә, инәгә – җеп...
Аңлашыла сүзсез дә.

## ОШАМЫЙ

Болытларның юмарт чагы,
Суы ташый чиләктән.
Көзге җилләр өченче көн
Яңгыр или иләктән.

Гомер иткән әби сөйли:
«Бу, – ди, – спасс яңгыры.
Өч көн үтми туктамас», – ди.
Озак, шайтан алгыры!

Төнме, көнме, әллә кичме –
Инде барсы буталды.
Шәһәр бүген көпә-көндез
Урамнарга ут алды.

И бу көзге яңгырларны
Булса икән туктатып.
Әйтерсең лә салкын тамчы
Тама җанга тып та тып.

Өйгә керә, сиңа сеңә
Салкын белән юеше.
Фасылына тел тидермим,
Тик ошамый бу эше!

## ИЗГЕ ТӨБӘК

Көн-төн поезд шпал саный,
Ялыккандыр бу эштән.
Кояшы да, арган сыман,
Офык артына төшкән.

Кан тартмаса, җан тарта шул,
Уйласаң – ерак ара.
Туган җирен сагынганнар
Өенә кайтып бара.

Ник бер нокта булсын җирдә,
Күчерергә карашны.
Бу төбәкнең кайсы төше
Сагынырга ярашлы?

Кем карап та берни күрми,
Кем уйларга бирелгән.
Аерылган шул бүген күпләр
Туган-үскән җиреннән.

Кемнәргәдер шушы дала
Газиз җир, изге төбәк.
Шулай тибәргә тиештер,
Уйласаң, һәрбер йөрәк.

## СТАДИОНДА

Капкачылар капкасын
Туп керүдән сакласын.
Сакчылар да үз исемен
Эше белән акласын.

Һөҗүмчеләр һөҗүм итсен,
Бу бит аларның эше.
Канәгатьлек алып китсен
Карарга килгән кеше.

Ике сәгать тартышуның
Нәтиҗәсе туп булсын.
Бер булса да ярый кайчак,
Ә иң шәбе – күп булсын.

Ни булса да, мөһиме шул –
Сезне халык яратсын.
Шаулап торсын стадион,
Җанатарлар җан атсын.

Тир түкмичә булмый анысы,
Туп кертүләр һай кыен.
Уртак булса да нәтиҗә,
Әмма ошады уен.

## ЧЫНЫ ШУЛАЙ

Тыңлап торсаң ышанасың:
Ит ясыйлар балыктан.
Пенсиягә йөз сум өстәп,
И көләләр халыктан.

Һәркайсына акча кирәк,
Дәүләт инде ялыккан.
Хәерчегә күлмәк алды,
Акча җыеп халыктан.

Болар нигә шулай дисәң,
Сагышлы йөз, арык тән?
Карт көнендә әби-бабай
Ит күрергә зарыккан.

Бәргәләнә күпме җаннар,
Чыга алмый калыптан.
Нигә шулай көләргәдер
Үлеп барган халыктан?

## ҮПКӘЛӘШКӘННӘН СОҢ

Чык бөртеге – җиләктә,
Ә җиләкләр – чиләктә.
Алып бирәм иң эресен,

Әгәр сиңа кирәксә.

Яшең кипкән битеңдә,
Үпкәң – ирен читендә.
Сиңа карап сүз кушарга
Уңайсыз да, читен дә.

Болыт килә, яшенле,
Аңа синең яшең ни!
Битләреңне юар, ахры,
Ул ниятен яшерми.

Куркыпмы каты җилдән,
Алгансың мине билдән.
Җылы яңгырга ияреп,
Мәхәббәтебез килгән.

## ЕЛЛАР БЕЗНЕ СИРӘКЛИ

Елатмагыз чәчен тартып,
Елатмагыз, кирәкми.
Нәрсә булган бу җилләргә –
Көн-төн яфрак сирәкли.

Елый каен, елый тирәк,
Чәчләр җиргә сибелгән.
«Кем эше бу?» диясе юк,
Җилләр чыкты чигеннән.

Басты дөнья мәшәкате,
Кайчак күрми кителә.
Айный кеше, сап-салкын яшь
Тамгач кына битенә.

Салкын җилгә барсы да бер –
Каен ни дә тирәк ни...
Әйтерсең без сары яфрак,
Еллар безне сирәкли...

## ШУНЫСЫ ЯХШЫ...

Без шулай да бу дөньяга
Саф сөюдән яралган.
Хәзер генә шактыебыз
Керләнгән дә каралган.

Дөньясына килү белән,
Һәммәбезне юганнар.
Без шушы җир кешеләре,
Бер уйласаң, туганнар.

Ничек тусак, шулай чиста
Юктыр инде сакланган.
Кайсы шактый, кайсы бераз,
Аз булса да тапланган.

Тәндә генә булса гаеп,
Төзәтәбез аны без.
Тәнне көн дә юып була,
Чиста булсын җаныбыз.

Кайсыбызда – тормыш табы,
Кайсы үзе буянган.
Шунсы яхшы: арабызда
Күп намусы уянган.

## БЕЗНЕҢ ҖИР

Шушы төбәк, шушы җирдән
Безгә илһам аласы.
Җанга иңгән гүзәллеген
Булыр җырга саласы.

Киткәннәрен шушы ярда
Безгә озатып каласы.
Кайтканнарын, якын итеп,
Булыр чәйгә аласы.

Тирә-якка нур бөркесә
Өйләренең яңасы,
Җиргә сеңгән искеләре –
Безнең йөрәк ярасы.

Үталмаслык саз булса да
Ике авыл арасы,
Күрше авыл кызы белән
Очрашуга барасы.

Бездә сыерның сөтлесе,
Бездә җирнең карасы.
Шушы җиргә орлык чәчеп,
Безгә уңыш аласы.

Ни булса да, бу – безнең җир,
Безгә тартып барасы.
Без бит җиргә тамыр җәйгән
Шушы авыл баласы.

## ИСКЕ ЕЛНЫ ОЗАТКАНДА

Төйнәп куйдым төен-төен
Кайгыларын, борчуларын.
Алсын әйдә үзе белән,
Озатыек төяп барын.

Барсы безгә ташлап китә,
Чүпкә батты инде җирем.
Сулу алсын кешеләре,
Маңгаеннан сөртеп тирен.

Үзе тапкан кризис бит,
Алсын, безгә калдырмасын.
Итен инде күрми халык,

Ипи-сөттән яздырмасын.

Авыруларын алсын тагы,
Наркотигын, папиросын.
Белмим ничек сыйдырырга
Вагонына шуның барсын.

Исәп быел Яңа елны
Каршыларга чистарынып.
Тузан, юшкын ишләрен дә
Юсак иде кырып-кырып.

## ОНЫТМА

Һәрчак болай булмастыр бит,
Күз яшьләрең бер кибәр;
Мәхәббәт тә килми калмас –
Син яшь әле, син чибәр.

Вакыт катламы астыннан
Сөю чишмәсе тибәр;
Канатланыр яшь күңелең –
Син яшь әле, син чибәр.

Теләсәң, җиһанны айка,
Теләсәң, җырлап җибәр;
Сиңа дигәне юлдадыр –
Син яшь әле, син чибәр.

Синең кебек сөйкемлегә
Сөйкемле сөяк диләр,
Һәр яңа көн алып килә
Бу җиргә әллә ниләр.

Мәңге болай була алмый,
Күз яшьләрең бер кибәр.
Балны яратмаганнар юк –
Шуны онытма, чибәр!

## ПАР КИЛГӘНСЕЗ

Икегез дә төз, матурлар,
Әйтерсең лә пар тирәк.
Пар килгәннәргә дә әле
Бәхетле булу кирәк.

Эзләсәң дә, еш очрамый
Бер матурга бер зирәк.
Бөтен парлар арасында
Пар килгәнсез бигерәк.

Шатлык өләшеп яшәгез
Һәм дә игелек кылып.
Шулчак бәхет касәгез дә
Торыр кырыннан тулып.

Белмим, кайда тугансыз сез
Һәм имгәнсез кем сөтен.
Минем өчен шунсы ачык:
Сез икегез бербөтен.

## ӘЛЛӘ ЖӘЛМЕ?

Сабый чакта ими тәмле,
Үскән чакта ипи тәмле.
«Чыннан да бу шулай», – дияр
Аңлаганнар минем хәлне.

Без дә менә үсеп җиттек,
Дөнья матур, яшәү ямьле.
Тик үзгәрде караш кына,
Барысыннан да сөю тәмле.

Оныттыра кайчак тормыш
Җанга иңгән шушы гамьне.
Ник әйтмисең «яратам» дип,
Сиңа шул сүз әллә жәлме?

Без булсак та, булмасак та,
Яшәр җирдә сөю мәңге.
Тәме китте авызымның,
Аера алмыйм кайчак тәмне.

Уздырмыйсы иде бушка
Бу мизгелне, шушы мәлне.
Ник әйтмисең «яратам» дип,
Әллә сиңа бер сүз жәлме?

## САГЫНУ

Калган чакта ил язмышы
Ачлы-туклы атларга,
Бүлеп каптык ипиләрне,
Теләп сезне сакларга.

Кулдан көрәк төшмәсә дә,
Булмады мантып кына.
Әллә кая киталмыйсың
«Уфалла» тартып кына.

Көрәк, сәнәк белән генә
Булмый зур эш майтарып.
Их, шул чактагы яшьлекне
Булса икән кайтарып!

Юк, танымас иде мәйдан
Җиңгән атның җайдагын –
Шаулатыр идек без дә бер
Сабантуйлар мәйданын.

## ШУНДЫЙ УЛ

Кайда күл дә, кайда елга –
Болыннарга тулган су.
Язлар җитсә, ярларыннан
Тулып ташый Чулман-су.

Әллә офыкларга кереп
Эрегәнме каршы яр?
Җәелгән бу Чулман-суда
Диңгез чалымнары бар.
Гаҗәпләнгән һәммәсе дә,
Сокланмаган юктыр һич.
Бу агымда чын олпатлык
Һәм баш бирмәс олы көч.

## КАПИТАН

Кичмәсәм дә диңгезне,
Күп урдым мин игенне.
Йөздем кыр корабында
Дулкыннар арасында.

Дулкын уйный суда да,
Дулкын чаба кырда да.
Үзгәрмәгән, шулай иде
Ул без үскән чорда да.

Диңгездә – дулкын явы,
Басуда – башак шавы,
Ә комбайн бункерында –
Алтындай икмәк тавы.

Ергаланган басу-кырлар,
Мин шуңа да сак йөртәм.
Минем диңгез – иген кыры,
Мин – комбайнёр-капитан.

## КИСКӘН ИКӘН...

Фотоңны да алып куйдым,
Хатлар да язмыйм хәзер.
Сүземдә торырга кирәк,
Әйткәнмен икән нәзер.

Тик исемең сискәндерә
Әле һаман юк-юкта.
Мин сиңа күбәләк түгел,
Кермәм кабат бу утка.

Агасы аккан инде,
Буласы булды күптән.
Чишалмас булып буталган
Икебез бергә сүткән.

Кискән икән ябышмас ул,

Өзәргә тек өзәргә.
Шундый авыр уйлар белән
Кереп барам көзләргә.

## ҖАНДА ШИГЫРЬ ӨЛГЕРӘ

Чәчәк диңгезеннән киләм,
Тирә-ягым гөл генә.
Тоеп йөрим – бөреләнде,
Җанда шигырь өлгерә.

Бирсен Ходай уңышлысын,
Болай булмый гел генә.
Төсмерләнде инде йөзе,
Сизеп киләм – өлгерә.

Тулгак тота күңелемне,
Шигырь туа, күр менә.
Игезәккә охшаганнар,
Булмас, ахры, бер генә.

Кытыклый ул эчтән сине,
Елата да көлдерә.
Шуңа ишарә инде бу –
Җанда шигырь өлгерә.

## КҮПМЕ КЫСКАРТЫРГА БУЛА?

Демократия килгәч,
И үрчеде түрәләр.
Бик аз эшләп күп алуны
Барсы да хуп күрәләр.

Кемгә кирәк артык кашык –
Кирәге юк эшченең.
Өстәвенә акча түлә –
Үзе күрсен үз көнен.

Бер эшчегә – бер нәчәлник,
Үрнәк безнең «Нефтехим».
Шундый була икән хәзер
Кыска күлмәк, озын җиң.

Әле һаман баш ваталар
Кыскартырга берәрсен.
Өстәгеләргә һаман да
Акча җитми, күрәмсең.

Быелгы бу кыскартуда
Мин яңалык күрмәдем.
Күпме була кыскартырга
Гел хатын-кыз күлмәген?..

## СКРИПКАЧЫ КЫЗГА

Гади генә скрипка
Һәм смычок кулыңда,
Ә уйныйсың кебек үзең
Минем күңел кылында.

Вакыт-вакыт чикерткәләр
Сайрый сыман болында.
Сере аның синең җанда,
Могҗизасы – кулыңда.

Гади кылдан чыккан аһәң
Дәшә безне күкләргә.
Дәваларга туган моң бу,
Якын шуңа күпләргә.

Йөзә җаннар моң эчендә,
Аңлашыла берсүзсез.
Бу моң гына, дисәләр дә,
Юк, югалмас бер эзсез.

Тыңласыннар авыз ачып,
Барсын үзеңә караттыр.
Синдә, сеңлем, Ходай биргән
Кабатланмас таланттыр.

## ҮЗГӘРЕШ

Бөтен дөнья ап-ак булган –
Кышка кереп барабыз.
Ышанмаганнар табылса,
Тәрәзәдән карагыз.

Эшен куеп бәйрәм итсен
Табынганнар аклыкка,
Һәм әйләнсен бу үзгәреш
Һәркем өчен шатлыкка.

Күзге сагыш җан кимерсә
Һәм бозылса арагыз,
Җаныгызга аклык иңәр,
Тиз төзәлер ярагыз.

Кайгырмагыз, ак кары да,
Кыш чыкканчы явам, ди.
Ни әйтсәң дә, ак ак инде,
Соры түгел, дәвалый.

Ак япмасын япкан җирем
Төн эчендә үзгәргән.
Мин шуңа да шигырь яздым
Бүген ап-ак сүзләрдән.

## ҖИТӘКЛӘШЕП КИТМИЛӘР

Кем беренче кулын биргән –
Мөһим түгел әллә ни.
Сизмәгәнбез, гомер уза,
Вакыт кырыс, җәлләми.

Кемгә кирәк, шул санасын
Ничә күлмәк туздырган.
Шунсы мөһим: безнең сыман
Бармы гомер уздырган?

Бүген дә без сезнең алга
Җитәкләшеп киләбез.
Көлик әле рәхәтләнеп,
Берәр кызык сөйләгез!

Ни язгандыр, булмый белеп,
Килә көлеп каласы.
Булмастыр бит бергә китеп,
Килмәсә дә каласы.

Ялгызлар ник еш елый да
Бәхетлеләр еш көлә?
Кемнәр китәр, кемнәр калыр –
Ни язганын кем белә?

## АВЫЛЫМ ГҮЗӘЛЕНӘ

Шушы төбәк баласымы,
Кем кызы син, үскәнем?
Белмәгәнмен авылыбызда
Алма тулып пешкәнен.

Бик тә уңган булачаксың,
Әниеңә охшасаң.
Туеңа да кайтыр идем,
Әгәр эштән бушасам.

Әтиең дә тирә-якта
Йөзек кашы, мактаулы,
Һәм шуңа да синең алда
Кирәк тапмыйм яклауны.

Күралмамдыр син алманың
Кем алдына төшкәнен.
Кайталсам-кайталмасам да,
Бәхетле бул, үскәнем!

## ҮЗЕМ ГЕНӘ

Белмәгәннәр сөйли кайчак:
«Яза, – дип, – җиңел генә».
Һәр почмагыннан кан тама,
Чыдасын күңел генә.

Белмим, күпме эзләгәнмен
Бүген бер сүзен менә.
Белмәгәннәр ни сөйләмәс...

Беләм тик үзем генә.

## БӘХЕТ ТУРЫНДА

Дусларга да туганнарга
Һәм сөйгәннәргә тагын
(Гадәткә кергәнгә микән)
Телиләр бары агын.

Сорап-сорап карасам да,
Белми беркем карасын.
Күңеленә ошый икән,
Һәркем үзе карасын.

Бәхет булгач, бер түгелме:
Агы ни, карасы ни?
Карасын эзләп тапкач та
Җитәкләп барасы, ди.

Җитәкләшеп атлаулары
Авыр микәнни шулай?
Авырсынмас идем бер дә,
Күбрәк бирсәңче, Ходай.

## КУЯН ХАТЫ

Сәбәбе нәрсәдә икән:
Куяннар быел азган.
Берсе әнә бүреләргә
Алан тутырып хат язган.

«Хатны укый алган гына
Мине табала», – дигән.
Бүре укып кулын куйган:
«Тапсам, чамала!» –дигән.

## ЯЛКЫН СҮНМӘСЕН

Караңгы төн. Яна учак.
Ялкын – учакның җаны.
Үземне аңлаган сыман
Аңларга телим аны.

Мәҗүсилек яши миндә,
Мәҗүси булмасам да.
Әллә шул учаклар төсе
Күчкәнме минем канга?

Ялкын сүнсә, күмер кала,
Кабыначак, өр генә.
Шулай учак тергезгәннәр
Булмагандыр бер генә.

Караңгы төн. Шомлы урман.
Берни түгел шул чакта,
Синең белән янәшәдә

Ут дөрләсә учакта.

Безгә уты кирәк булса,
Үләнгә – учак көле.
Җаныңның ялкыны сүнсә,
Син инде ярты үле.

## МИН ШУНДЫЙ

Күршеләрем шәп булса да,
Сәбәпсез кергәнем юк.
Авыр чакта тешне кысам,
Тик елап йөргәнем юк.

Эчтәген дошман алдына
Чыгарып элгәнем юк.
Кеше кайгысына басып,
Югары менгәнем юк.

Шатлыгымны барысы белә,
Эчемә күмгәнем юк.
Икейөзле булу өчен,
Икенче күлмәгем юк.

Ярап булмый һәркемгә дә,
Булып булмый гел уңай.
Теләгәннәр аңлар әле,
Ничек бар – язам шулай.

## БЕЛЕГЕЗ!

Кызлар көлә, мин елмаям,
Бер сүзем юк, көлегез.
Тиздән минеке булачак
Арагыздан берегез.

Җаны назга сусаганны
Шаяртмыйлар күз атып.
Шушы караш җитә калды,
Киттең җанны кузгатып.

Озын керфек асларыннан
Ник төбәлдең йөземә?
Мин гаепле түгел, сеңлем,
Син үпкәлә үзеңә.

Кыяфәтең әйтеп тора:
Син шаянсың, шук, беләм,
Тик син аңлар яшьтә инде,
Шаярмыйлар ут белән.

Сезнең әле көләр вакыт,
Әмма шуны белегез:
Беркөн минеке булачак
Арагыздан берегез.

## КИТКӘН БУЛЫР

Яшьлек бит матур бер хыял,
Кул болгап киткән булыр.
Күбебез аңлап җиткерми,
Кайтыр дип көткән булыр.

Кызлар үргән чәч толымын
Таратып сүткән булыр.
Безнең дә әле ярларны
Уятып үпкән булыр.

Эшлисе эшләрне уйлап,
Планнар корган булыр.
Янәшәдә сөйгән ярлар
Елмаеп торган булыр.

Җитәр бер көн – чәч-кашларны
Ак белән чиккән булыр.
Кара чәчең искә төшеп,
Шул чакта күңел тулыр.

Күз салырбыз тирә-якка –
Кемнәрдер киткән булыр.
Гомер дигән кыска юлның
Азагы җиткән булыр...

## КАГЫЛДЫ

Сөйләнсә дә өстәгеләр:
«Бу, – дип, – безгә кагылмый».
Көнбатыштан көнчыгышка
Болыт юкка агылмый.

Бу элекке заман түгел,
Хәзер капка ябылмый.
Булмады шул бу юлы да
Үткәннәрне сагынмый.

Сезгә, бәлки, җил дә тимәс,
Безгә менә кагылды.
Астагыларның күбесе
Инде кайгы ябынды.

Бу кризис дигәннәре
Ачты салды ялганны –
Түләргә кирәк икән бит
Әҗәткә дип алганны.

Алдадылар «кагылмый» дип –
Шактый каты кагылды.
Әйбәт кенә барган җирдән
Ил яңадан абынды.

## БЕЗ БАШКА

Җилкәненә җил киереп,
Дулкын чаба офыкка.
Беләсезме, бу ашыгу,
Бер уйласаң, гел юкка.

Офыкларда, каршы басып,
Көтә аны таш кыя.
Баш бирмәстәй чапкан дулкын
Ташка килеп баш куя.

Кирәк икән, иссен җилләр,
Суда дулкын уйнасын.
Бары кеше бер кисәсен
Җиде кабат уйласын.

## ЯЛГАН ЯХШЫГА ИЛТМИ

Учакта янган булды,
Күмергә калган булды.
И риясыз җан булганмын,
Барсы да ялган булды.

Төн куна калган булды,
Кирәкне алган булды.
«Яратам», – дип сөйләнсәк тә,
Болар бит ялган булды.

Әз генә салган булдым,
Шуңамы күңел тулды.
Хәзер алдашмас та идем,
Болар шул күптән булды.

## ГАШЫЙКМЫН

Хатлар язсам да төн буе,
Хисләрдән бушаналмыйм.
«Җил артыннан җибәр», – дисең,
Юк, җилгә ышаналмыйм.

Сөйләшмичә булмас, ахры,
Иңне иңнәргә куеп.
Салсаң икән мин әйткәнне
Күңелләренә уеп.

Тапты күңел үз дигәнен,
Үзенә ошаганын.
Тик көтәргә риза түгел
Урынның бушаганын.

Газаплама вакыт сузып,
Сынама түземлекне.
Булачаксың син, чынлап та,
Бары тик үземнеке.

«Түзәргә кирәк беразга,

Бу, – дисең, – вакыт эше».
Тимер булсам, түзәр идем,
Мин бит бер гади кеше.

## САГЫНУ

Карап торам болытларның
Шул якка агылуын.
Аңлашыладыр шуннан да
Ничекләр сагынуым.

Узган гомер уза икән,
Нигәдер искәрмәдем.
Озатып калам җилләрнең дә
Шул якка искәннәрен.

Кайтып булмый һәр ай саен,
Белсәм дә көткәннәрен.
Уңмас бизәк, ак хатирә –
Яшьлегем, үткәннәрем.

Туган яклар бизәк булып
Уелган күңелләргә.
Менә шундый шигырь туды,
Җаннан хис түгелгәндә.

## ҮЗ ЮЛЫМ

Җырлап карыйм – тавышым юк,
Гармун тартам – көй чыкмый.
Аңлый да кеше сәләтен
Андый эштән бер туктый.

Меңләгән эш арасында
Бардыр миңа дигәне.
Юктыр бары күңелемнең
Әле чынлап сөйгәне.

Кемнәргәдер күп бирелгән,
Кемнәргәдер – кимрәк.
И, табасы килә кайчак
Үзеңнекен тизрәк.

Йөри дә кеше адашып,
Чыга бер туры юлга.
Һәм әйтәләр, аңа карап:
«Бу, – дип, – үз урынында».

Үз юлым бар, үз фикерем,
Тормышта үз урыным.
Мин бу җирнең ак күңелле,
Саф җанлы бер улымын.

## ЯБЫГЫЗ

Булмаса да япканы,
Җил ачкан җилкапканы.
Ишетелә эчке яктан
Челтерәп су акканы.

Булмаса да япканы,
Җил ачкан җилкапканы.
Аккан сулар юлын табар,
Туктату юк акканны.

Булмаса да япканы,
Җил ачкан җилкапканы.
Яхшы түгел ятка бирү
Үзең эшләп тапканны.

Алмый кеше ятканны,
Ала мактап сатканны.
Юкса тагы шигырь язам,
Яп, күрше, җилкапкаңны!

## АЛМА САТКАНДА

Алмагачлар балкыган чак
Бакчаларда ал булып.
Тулган алма эчләренә
Кояш нуры бал булып.

Алма сата авылдашлар,
Җиткән алма сәгате.
Сакларга иде ничек тә
Шушы матур гадәтне.

Тезелгәннәр юл читенә
Алма битле апалар.
Туктап калган юлчыларга
Мактап алма саталар.

Бер алмага карый юлчы,
Бер – апамның йөзенә.
Апам әллә алма булып
Күренә инде күзенә?

## СУ БУЕ

Яр астының яшь таллары
Карый ярдан үрелеп.
Туган якның матурлыгы
Бетмидер шул күренеп.

Җәй кояшы төшеп бара,
Арган, ахры, кыздырып.
Сандугачлар җыр сузалар,
Берсен берсе уздырып.
Яр астының үз аһәңе,
Кабатламый беркемне.
Чөкердәшеп кайтып бара

Казларның бер төркеме.

Су керермен дигән идем
Тирләп төшкән килешкә,
Кыймый торам куркытырга –
Балык уйный инештә.

Таллар суга кармак салган,
Әллә балык каптыра.
Шушы инеш искә төшсә,
Һәрчак күңел яктыра.

## КЕШЕ КАЙЧАН БӘХЕТЛЕ?

«Мин дә бит шагыйрь» диеп
Йөргән чак, башны чөеп.
Күк капкасы ачылганмы –
Йолдызлар биек-биек.

«Мин нинди шагыйрь?» диеп
Йөргән чак, башны иеп.
Агач ботаклары иңгә
Калалар тиеп-тиеп.

Бүген чынлап бәхетлемен,
Күңелем белән бөек –
Син бит миңа тәүге тапкыр
Карадың шулай сөеп.

## КИСӘТҮ

Күпләр инде эреп югалганнар,
Басып йөрим алар көленә.
Тарих чоңгылларын кичкән халкым,
Бөеклегең бүген беленә.

Кайберәүләр һаман өмет итә,
Яшәү көчен безнең туймыйлар.
И телиләр безне киметергә,
Кимсетергә әмма кыймыйлар.

Бу җирләрдә безнең эзләр тирән,
Тарихларда – халкым үткәне.
Өметләнгәннәргә минем җавап:
Күралмассыз безнең беткәнне.

Укысагыз иде чын тарихны,
Уйлансагыз иде тукталып.
Хөрмәт белән кайчак баш исәк тә,
Баш кистермәс безнең бу халык!

# ЯҢГЫР ЯВА ОЕП КЫНА

Табигатьнең серле чагы,
Яңгыр ява оеп кына.
Атлап киләм ашыкмыйча,
Бар рәхәтен тоеп кына.

Йөреп булмый мондый чакта
Яшь агызып, боек кына.
Сафландырган һаваларны,
Яңгыр ява оеп кына.

Ун минутта күлләр ясап
Киткәне бар коеп кына.
Минем күңел теләгәнчә,
Ява бүген оеп кына.

Бу – Ходайның рәхмәтедер,
Болыты да сыек кына.
Эчә җиһан җылы яңгыр,
Рәхәтләнеп, оеп кына.

Дөньясында сирәк мизгел –
Яңгыр ява оеп кына.
Күңелемдә шигырь туган,
Әйтим дисәм җыеп кына.

# СИН ДӘ ЧИТТӘ КАЛМАССЫҢ

Һәрберегез җавап бирер...

*В. Жириновский*

Унбиш еллап нидер сөйли,
Аңламыйбыз әмма без.
Үзгәртүләр чоры белән
Миңгерәйгән хәлдә без.

Әйткән сүзе и шәп тә соң:
«Җавап тотар һәммәгез!»
Кемгә шундый таләп икән,
Гаепләме әллә без?

Һәммәсенә кул селтәрдәй
Әллә артык баймы без?
Сайлау җитсә, уйлап тормый
Һаман аны сайлыйбыз.

Бармы җирдә акыллылар?
Булса, безне җәлләгез –
Илдә нәрсә барганны да
Аңламаслык хәлдә без.

Чиге булыр, туяр халык,
Сүзсез калып туктарсыз.
Сез дә бер көн безнең белән
Бергә җавап тотарсыз.

## ЯЗАРГА ДА ЯЗАРГА

Ил турында, ир турында
Уйланам кайта-кайта:
Язганым гына юк әле,
Бу инде минем хата.

Берәүләр белдекле булып
Туктаусыз акыл сата.
Язарга кирәк моны да,
Онтылыр ята-ята.

Язучылар, тема юк, дип
Зарланалар еш кына.
Тема бар ул, бары күңел
Булмасын тик буш кына.

Хатирәләр башка сыймый –
Бу халәт туган якта.
Ә күпме язарга була,
Уйласаң шушы хакта.

Башлап китәм бисмилладан,
Шунсыз эшем һич уңмый.
Язарга күңел булганчы,
Аз язсам, күңел булмый.

## КЫШКЫ ТАБЫШЫМ

Өсләреңә карлар кунган,
Ятмасын, кагыйм әле.
Күрмәм микән үз-үземне –
Күзеңә багыйм әле.

Чәчләреңә карлар кунган,
Кар кызы булгансың ич.
Бир кулларыңны, җылытам,
Кызарып туңгансың ич.

Керфегеңдә карлар эри,
Ачуланма кагылсам.
Рөхсәттер бит Кар кызына
Моннан соң да табынсам?

Гаҗәп түгел, салкын кышта
Миләш булып кабынсам.
Кыштан мине эзләп йөрмә,
Тик хәбәр бир сагынсаң.

Таш яуса да килеп җитәм,
Бернәрсәгә карамый.
Аңлашулар көткәннәргә
Очрашмыйча ярамый.

## НИШЛӘРГӘ?

Ята елап яр астында
Кышның актыккы кары.
Күңелдә боз кисәгедәй
Мәхәббәт ватыклары.

Аттым беркөн барсын җыеп
Ике боз арасына,
Юкса тиеп йөдәтәләр
Йөрәгем ярасына.

Сагыш белән нишләргәдер,
Булмый суга атып та.
Дәваласа ул дәвалар,
Бар ышаныч – вакытта.

## БЕЗ ҖАВАПЛЫ

Җиңел микән яшәүләре
Җирдә бүгенгеләргә?
Кыен микән ак кышларда
Кара күңеллеләргә?

Көз дип нигә моңаерга,
Бер сәбәп тә юк сыман.
Күккә карап елап булмый,
Җитә болыт үксегән.

Сәбәпләрен белмәсәм дә,
Гел җылыга тартылам.
Тик шулай да китеп булмый
Киткән кошлар артыннан.
Йөрәк кайчак, кызып китеп,
Үз читлеген тарсына.
Акыл йөрсен һәрчак алдан,
Кызма, йөрәк, ярсыма!

Җирдә кайдан хәвеф яный,
Чыгып басыйк каршына.
Ни булса да без җаваплы
Җирдә бүген барсына.

## СИҢА

Колакларымны кытыклый
Ярату тулы тының.
Ә бокалдагы шәрабта
Чайкала шәрә сының.

Кулларың салкын еландай,
Күзләрең – утлы күмер.
Безнең белән таңга чаклы
Мәхәббәт үзе булыр.

И ул сөю дигәненең
Исерткеч татлы тәме!

Озата бар мәңге шулай,
Ташлама мине, яме.

## АГАБЫЗ

Берни түгел аңа синең
Юбилей табының да.
Вакыт өчен һәркем тигез,
Агабыз агымында.

Уфтанма да, үкенмә дә,
Ни әйтим зарларыңа?
Калырга теләп агымыннан
Эзләмә ярларын да.

Ялгышма кичәргә уйлап,
Тапмассың басмаларын.
Аңларсың бу хыялларың
Тормышка ашмаганын.

Булмый алдан чабып та,
Булмый туктап калып та.
Вакыт дигәннәрен хәтта
Булмый сатып алып та.

Ага вакыт, чаба вакыт,
Агымы бар, яры юк.
Тукталышың шушы дисә,
Юлың тәмам, ары – юк.

## БАРЫП ҖИТТЕК

Гаепле микән бу эштә
Койма йә киртә генә?
Абау, сеңлем, нәрсә булды
Бу күлмәк итәгеңә?

Җитә калыр азгыннарга,
Нәрсә дияр күргәннәр:
«Бу эләгеп ертылмаган,
Кайчы белән телгәннәр».

Хәзер моны мода диләр,
Гаепләмәс белгәннәр.
Ил иректе, без ирекле,
Көлсен әйдә көлгәннәр.

Байлык хәзер күз алдында,
Ачып салдык түшне дә.
Бик теләсәң күреп була
Хәтта теге төшне дә.

Ачык түш һәм ачык кендек
Ике кызның берсендә.
Юкса озак яшәмәссең,
Абзый, авыр көрсенмә.

Кайсы якны алсак та без,
Юктыр безгә тиңнәре.
Безнең илдә яши хәзер
Дөньяның иң-иңнәре.

## УНҖИДЕ

Таныш түгел әле миңа
Сагыш иле, моң иле.
Мин – ачылып килгән чәчәк,
Тула бүген унҗиде.

Сөю исен сизгән җанны
Тышка дәшә яз җиле.
Алда серле дөнья ята,
Ә балаңа – унҗиде.

Башка булмас, тануыдыр,
Яшьлек килеп баш иде.
Аяк җирне тоймас чаклар,
Бу балаңа унҗиде.

Тоткан юлым, кылган эшем
Моңа чаклы уң иде.
Керсез җаным сөю көтә –
Миңа инде унҗиде!

## АҢЛЫЙ БАРАБЫЗ

Ява җиргә төсле яңгыр,
Агачлар яфрак коя.
Моңая, көзләргә охшап,
Кошлары киткән оя.

Күрә белсәң, күптер мәгънә
Без яшәгән дөньяда.
Сары яфрак – сары юрган,
Җылы саклый ояда.

Шыбыр-шыбыр яңгыр ява,
Көзге яңгыр үзе көй.
Сагышлана шушы көйгә
Ялгыз оя – ялгыз өй.

Туган нигез – изге ядкяр,
Килми һич тә җуясы.
Кошларның да үз нигезе,
Үстергән үз оясы.

Язлар гына килсен җиргә,
Җанланачак бу оя.
Аңлый барабыз дөньяны,
Тапканны җуя-җуя.

## ӘЛЕ ЯРЫЙ КАГЫЛДЫМ

Сине кулыңнан алып,
Кофтаңны иңгә салып,
Атладык елга ярыннан,
Җилне икегә ярып.

Калалар карап-карап,
Йөрмибез вакыт санап.
Җилләр ятты ял итәргә,
Аргач чәчеңне тарап.

Кулым тиде битеңә,
Аннан ирен читеңә.
Шунда бераз туктап калдым
Иренеңә җиттем дә.

Вакыт та бетә иде,
Тимәсәм үтә иде.
Юк шул, синең сусыл ирен
Кагылу көтә иде.

Син кердең кочагыма,
Мин кердем кочагыңа.
Янабыз, тик курыкмагыз,
Без – сөю учагында.

## БЕЗДӘ ШУЛАЙ

Нәрсә дисең инде моңа –
Дивана бездә халык:
Сазлыктан бакча ясый да
Дәүләткә түли налог.

Өй буендагы газонга
Хуҗа икән хәзер без.
Анысына да акча, диләр –
Каршы түгел, әзер без.

Уйчан караш, чытык чырай,
Йөри күпләр баш иеп.
Эчә халык бар булганын,
Дәүләт алганчы диеп.

Авыз ачып әйтер идең,
Ачсаң, үпкә күренә.
Алыр әйберең калмаса,
Дәүләт шуңа үренә.

Сораучы юк «бармы?» диеп,
Йөдәтәләр таптырып.
Шуңа салым планы да
Үтәлә гел арттырып.

## КАЙЧАН КИЛЕР?

Утырталар тәхетләргә,
Артыннан этә-этә.
Гомер елгасы сай димим,
Язмыш ярлары текә.

Законнар юк дөньясында,
Шуңа дөнья азгандыр.
Безне арттан этүче юк,
Безгә ниләр язгандыр.

Килми бәхет эзләсәк тә,
Китәргә вакыт җитә.
Инде чәчләр дә агарды,
Килгәнен көтә-көтә.

Белмим, көткән килер микән,
Икеләнәм, оланнар.
Ил белән идарә итә
Бездә хәзер кланнар.

## ҮЗЕМ БАРАМ

Җил булсам туктатыр идем,
Итәкләреңнән тартып.
Нишләргә соң инде хәзер,
Ачуланыштык артык.

Җил булсам туктатыр идем,
Юлыңа каршы басып.
Зиһенне, аңны каплады
Ачу дигәне, ташып.

Җил булсам туктатыр идем,
Кулыңнан гына тотып.
Басылдым, үкенүләрне
Утырам эчкә йотып.

Җил булсам туктатыр идем,
Тик иңнәреңнән кочып.
Уйлар кагылырга кыймый,
Яныңда йөри очып.

Яннарыңа үзем барам,
Хисләрне булмый тыеп.
Үкенмәс идем аерылсак,
Бер-беребездән туеп.

## КҮРИМ ДИСӘҢ

Бәхетледер кешеләрнең
Авылда туганнары.
Чистарактыр керләрнең дә
Чишмәдә юганнары.

И ул җиләкле аланнар,
И ул авыл таңнары!
Авылдашларымның хәтта
Керсездер күк җаннары.

Бар да якын, бар да таныш,
Каз каңгылдый, эт өрә.
Авыл синең кемлегеңне
Туган көнеңнән белә.

Йолдызлар да күпкә якты
Төнге авыл күгендә.
Алар безгә охшамаган,
Элеккечә бүген дә.

Аңлар микән авыл ямен
Чыланмаган чыкларга.
Гашыйкмын яз могҗизасы –
Гади сыерчыкларга.

Һәр авылның үз диңгезе,
Чайкала иген кыры...
Ничек барсын күрим дисәң,
Кайт үзебезгә туры.

## ҖӘЙГЕ ТӨН

Куера бара караңгы,
Җир өстенә төн иңә.
Мөһим түгел безгә анысы –
Кем җиңелә, кем җиңә.

Бөркәнә күк гөмбәзе дә
Йолдызлы кара яулык.
Җәйнең җылы рәхәт киче
Бу бит үзе зур саулык.

Урамга чыккан һәммәсе
Җиңелчә киенгән дә.
Төн куенына елыша
Сөйгән дә, сөелгән дә.

Сулыйм дисәң – һавасы саф,
Йөрим дисәң – юл такыр.
Тиздән гашыйкларга юлдаш
Яңа туган ай калкыр.

Ял итәләр кайсы ничек,
Кемдер басып гәп кора.
Дымы да бар, җылысы да –
Җәйләр быел шәп тора.

Әйдә бераз йөреп килик,
Сагындырыр кыш көне.
Шәбен шәп тә, керми булмас,
Иртәгә бит эш көне.

* * *

Җирдә кояш булып булмый,
Күктә яшен яшьнәгәндә.
Бик тә кыен бу дөньяда,
Артык дөрес яшәгәндә.

Күккә карап елап булмый,
Күзен болыт үксегәндә.
Юмарт чакта бирә Ходай,
Кире ала күпсенгәндә.

Вакыт узгач басылырсың,
Әйдә ела, ачыргалан.
Әмма ләкин балланалмый
Теләсәң дә ачы балан.

Зур эшләрне эшләп була,
Булсаң гына барың бергә.
Күмәк эшнең шунсы яхшы –
Җиңелрәк барыбер дә.

## БЕЗНЕҢ ӘБИЛӘР

Чәчәк күргәч, гөл дип торам –
Тәрәзә өлгесе бу.
Самавырда кояш уйный –
Чисталык билгесе бу.

Инәсенә җеп сапланган,
Бармагында уймагы.
Мич алдында кунак көтә
Яңа пешкән коймагы.

Йөзе – якты, сүзе – тәмле,
Өстәлендә – ак җәймә.
Самавыры җырлап тора,
Чакырып сине чәйгә.

Һәр кергәнне кунак итә,
Чәй эчерми чыгармый.
Яхшы беләә әби шуны:
Яхшылык ул югалмый.

Вакыт табып намаз укый,
Оек бәйли, җеп эрли.
Безнекеләр хәер эстәп
Базар буенда йөрми.

Бөтерелә үз өендә
Күгәрчен сыман гөрләп –
Безнең татар әбиләре
Дөньясына бер үрнәк.

## АК ПАТШАЛЫК

Бәс ябынган яшь талларның
Ул серле гүзәллеге!
Кабатланмас ак патшалык –

Су буе үзәнлеге.

Кар өстендә кояш уйный,
Күзләрне камаштырып.
Кайтып киләм су буеннан,
Сагышны адаштырып.

Кызылтүшләр миләш чүпли,
Хәбәрләшеп үзара.
Кышка кергәч алар, ахры,
Миләш ашап кызара.

Берни түгел кыш чишмәгә –
Агып ята улактан.
Салкын бары мине генә
Чеметкәли колактан.

Бу әкият патшалыгын,
Белмим, кемнәр күргәндер.
Әмма бүген бу җиһанда
Мин әлегә бердәнбер.

## БЕЗ ИРЕКЛЕ

Басмаган бу басуларга
Күптән кеше аяклары.
Бу кырларның чын хуҗасы
Бүген шайтан таяклары.

Без бит күреп үскән идек
Игенчене зурлаганны.
Булмагандыр бер чорның да
Җирне болай хурлаганы.

Ирек бүген һәркемгә дә:
Тели – чәчә, тели – чәчми.
Җир хуҗасы без булганга,
Башкалары берни дәшми.

Каян тапса, шуны ашый,
Ничек тели, шулай кия.
Шундый икән ул яңа сүз –
Бөек демократия.

## СОКЛАНАМ

«Миләш белән балан, – дисез, –
Табигать бизәкләре».
Миңа калса, алар әле
Бер ана игезәкләре.

Кыраулар да тик файдага,
Куркытмый көзге салкын.
Алар гүя сихри учак,
Эчләре тулы ялкын.
Ике туган ике яктан
Ямь бөркиләр аланга.

Яшим гомергә сокланып
Миләш белән баланга.

## ЮЛЫҢ УҢСЫН!

Сары нарат бүрәнәдән
Һәм ап-ак калай түбә,
Әллә кояш танышымы –
Кояшка карап көлә.

Капкалары челтәр-челтәр,
Төсе матур яшелдән.
Эчке якта кемдер җырлый –
Бездән капка яшергән.

Җырлаучысы яшь кыз бугай,
Шаярганга охшаган.
Урам якта егет тора,
Мәхәббәткә сусаган.

Кемдер керер, кемдер чыгар –
Капка бит шуның өчен.
Бу капка янына егет
Киләчәк әле кичен.

Мәхәббәт ул – йөрәк эше,
Истән чыгарма шунысын.
Теләгем шул сиңа, дустым,
Кич килгәч, юлың уңсын!

## ЯҢА ЕЛЛАР

Үзгәрәбез заман белән,
Үтә гомер, яна еллар.
Элеккедәй шатландырмый
Хәзер килгән яңа еллар.

Көтеп тора һәрнәрсәгә
Яңа елдан яңа бәя.
Ил өстенә әкрен генә
Хәерчелек канат җәя.

Төзелсә дә яңа йортлар,
Ачылса да яңа юллар –
Шомландыра һәм куркыта
Алда торган яңа еллар.

Ялга чыгып, ял белмиләр
Сөялләнгән ябык куллар.
Үзгәрмәсме яхшы якка,
Килми торса яңа еллар.

Үтә гомер сызып кына,
Файдасызга яна еллар.
Карамыйча бернәрсәгә,

Килә тора яңа еллар.

## ОНЫТМАГАН

Җир җиләге җыеп чеме белән
Менеп киләм болын юлыннан.
Онытмаган әле җылы җилләр,
Сине эзли һаман куеннан.

Айкый хәтер ерак үткәннәрне,
Чыкмагансың икән уемнан.
Тик шулай да элеккечә түгел,
Нәрсәләрдер инде җуелган.

Хәтер йомгакларын сүтә-сүтә
Кайтып киләм болын юлыннан.
Елмаюың белән зифа сының
Йөрәгемә гүя уелган.

Әйтерсең лә болын минем күңел,
Печәннәре инде җыелган.
Искә төште, якты мизгел булып,
Кайтуыбыз икәү бу юлдан.

Иң соңгысы булып алга килде
Чыгып китүләрем туеңнан.
Уза гомер шулай сәер генә,
Очрашулар безгә тыелган.

Еллар булып хатирәләр ага,
Кайтып киләм болын буеннан.
Җилләр әле безне онытмаган,
Сине эзли һаман куеннан.

## СӘЕР ЯНГЫН

Усакны ялкын чорнаган,
Өрәңге очкын чәчә.
Урман өсләрендә янгын –
Бу шулай офыккача.

Җилләр оятны оныткан,
Каенның тәнен ача.
Кояш, күзем күрмәсен дип,
Офыкка кереп кача.

Ялкын эчендә калганбыз –
Дөньясына ут капкан.
Әллә нинди серле янгын,
Күренми куркып чапкан.

Кычкырмыйлар «Янабыз!» дип,
Чыкмый кара төтен дә.
Ята бирә оясында,
Һич борчылмый этем дә.

Агачлар да исән-саулар,
Ботак саен бөре гел.
Язга гына чыгыйк менә,
Барсы кабат терелер.

## ҮЗГӘРЕШ

Кая шулай ашыгасың,
Арттан язмыш кугандай,
Каранасың як-ягыңа,
Кемеңнедер җуйгандай.

Кая шулай ашыгасың,
Дөньясыннан туйгандай.
Озата бара баш очыңнан
Моңсу гына тулган ай.

Кая шулай ашыгасың,
Артыңа ут капкандай,
Кинәт кенә туктап калдың,
Кемеңнедер тапкандай.

Күзләреңә кояш кунды,
Йөзең яңа югандай,
Елмаясың дөньясына,
Җиргә яңа тугандай.

## ЭЧТӘЛЕК

**Күңелнең бөек мәле**


Агымсу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Август киче . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Нигә шулай? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Туя алганым юк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кирәк түгел уртагы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Җиләкле алан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Аңламыйлар шуңа безне . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Сыналдык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Безнең инеш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Аңламый . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Минем кебек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Моңаю . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Йа Раббым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Үземнеке үзәктә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Агалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Заман чире . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кирәктер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Бүре йөри, эт өрә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Гүзәлләр бәйгесендә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Хушлашу . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Булалмамдыр фәрештә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

«Тормышта да, шигырьдә дә...» . . . . . . . . . . . . . . . .
Әбиләр чуагы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Сезне җәлләп . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Алма коелган чаклар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Без шул . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Үпкәм юк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Аңласыннар иде . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Түбән Кама . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Яшәү – көрәш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Бар өметем язларда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Әле ярый әйләнә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Таптык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
«Күңел аклыгы кердә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
«Кергәч кеше көзенә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
«Чебен ябышкан балга...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
«Яшел газон, сары яфрак...» . . . . . . . . . . . . . . . . .
Онытканмын әдәпне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Гарасат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Халык авыз иҗаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Табышмаклар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Инеш буенда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Туган якка мәдхия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Көзге урман . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Борчылып . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кире кайтмый . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Дөресме? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
«Рамиле монда икән...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Шулай язган . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кыюсыз кыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Мәхәббәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Вакыт әйтер . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Иң-иңе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Вакыт – елга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Булыр микән? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Уйлаганчы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Шундыйлар да булгалый . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Борчылмагыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кайсыгыз белә? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кояш турында җыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Язгы уяну . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Үзем турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

**Таң яктысы**

Мин рәхмәтле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Аңлашыла . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Ошамый . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Изге төбәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Стадионда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Чыны шулай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Үпкәләшкәннән соң . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Еллар безне сирәкли . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Шунысы яхшы... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Безнең җир . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Иске елны озатканда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Онытма . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Пар килгәнсез . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Әллә җәлме? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Сагыну . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Шундый ул . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Капитан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Кискән икән... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Җанда шигырь өлгерә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Күпме кыскартырга була? . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Скрипкачы кызга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Үзгәреш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Җитәкләшеп китмиләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Авылым гүзәленә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Үзем генә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Бәхет турында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Куян хаты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Ялкын сүнмәсен . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Мин шундый . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Белегез! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Киткән булыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кагылды . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Без башка . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Ялган яхшыга илтми . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Гашыйкмын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Сагыну . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Үз юлым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Ябыгыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Алма сатканда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Су буе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кеше кайчан бәхетле? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кисәтү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Яңгыр ява оеп кына . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Син дә читтә калмассың . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Язарга да язарга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кышкы табышым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Нишләргә? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Без җаваплы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Сиңа . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Агабыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Барып җиттек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Унҗиде . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Аңлый барабыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Әле ярый кагылдым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Бездә шулай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Кайчан килер? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Үзем барам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Күрим дисәң . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Җәйге төн . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
«Җирдә кояш булып булмый...» . . . . . . . . . . . . . .
Безнең әбиләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Ак патшалык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Без ирекле . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Сокланам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Юлың уңсын! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Яңа еллар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Онытмаган . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Сәер янгын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .
Үзгәреш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Литературно-художественное издание

**Имаев** Рифкать
(**Имаиев** Рифкать Гаянович)

ТЕЧЁТ РЕКА

Казань. Татарское книжное издательство. 2012

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Имаев** Рифкать
(**Имаиев** Рифкать Гаян улы)

АГЫМСУ

Мөхәррире *Ф. И. Фәтхетдинова*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *М. Д. Вазиева*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Ф. Р. Гыйсмәтуллина*
Корректоры *Г. М. Хәбибуллина*

Оригинал-макет-тан басар-га кул куелды 2.05.12. Форматы 70×90 $^1/_{32}$.
Басма табагы 4,68. Ти-ражы 1100 д. За-каз

«Та-тарстан китап нәш-рияты» ДУП. 420111. Ка-зан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

**Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып алырга мөмкин:**

Ка-зан, Де-каб-ристлар урамы, 2.
Та-тарстан китап нәш-риятының маркетинг бүлеге. Тел.: (843) 519-45-35.
Ка-зан, Бауман урамы, 29/11.
Та-тарстан китап нәш-риятының фирма кибете. Тел.: (843) 292-03-18.

«Татмедиа» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиг-рафия-нәш-рият комплек-сы.
420066. Ка-зан, Де-каб-ристлар урамы, 2.